| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.12.2018 Казан ш. № 10-133/кс

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 8 декабрендәге 10-108/кс номерлы карары белән билгеләнгән "Су чистарту станциясе – ТүбәнКамаНефтехим" акционер җәмгыяте өчен 2019 елга салкын суны транспортировкалауга озак вакытка исәпләнгән тарифларны үзгәртү турында

"Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару турында" 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында" 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында" 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, салкын суны транспортировкалауга озак вакытка исәпләнгән тарифларны һәм җайга салына торган оешманың кирәкле тулаем табышын үзгәртү максатларында Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының "Су чистарту станциясе – ТүбәнКамаНефтехим" акционер җәмгыяте өчен 2018 - 2020 елларга салкын суны транспортировкалауга тарифлар билгеләү турында" 2017 елның 8 декабрендәге 10-108/кс номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
2017 елның 8 декабрендәге 10-108/кс номерлы карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
2018 елның 7 декабрендәге 10-133/кс номерлы карары редакциясендә)

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы "Су чистарту станциясе -ТүбәнКамаНефтехим" акционер җәмгыяте өчен 2018 – 2020 елларга, календарь бүленештә күрсәтеп, салкын суны транспортировкалауга тарифлар

| № т/б | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме | Салкын суны транспортировкалауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | |
| | | 2018 елның 1 гыйнварыннан алып 2018 елның 30 июненә кадәр | 2018 елның 1 июленнән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр | 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 30 июненә кадәр | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр | 2020 елның 1 гыйнварыннан алып 2020 елның 30 июненә кадәр | 2020 елның 1 июленнән алып 2020 елның 31 декабренә кадәр |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | "Су чистарту станциясе -ТүбәнКамаНефтехим" акционер җәмгыяте (тарифларны күрсәткәндә НДС исәпкә алынмады) | 3,14 | 3,19 | 1,30 | 1,30 | 1,30 | 1,33 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
2017 елның 8 декабрендәге 10-108/кс номерлы карарына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
2018 елның 7 декабрендәге 10-133/кс номерлы карары редакциясендә)

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы "Су чистарту станциясе -ТүбәнКамаНефтехим" акционер җәмгыяте өчен 2018 – 2020 елларга салкын суны транспортировкалауга тарифларны җайга салуның озак вакытка каралган параметрлары

| № т/б | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме, тариф төре | Ел | Операцион чыгымнарның нигез дәрәҗәсе | Операцион чыгымнарның нәтиҗәлелеге индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | су югалту дәрәҗәсе | электр энергиясенең чагыштырма кулланылышы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·сәг./куб.м |
| 1 | "Су чистарту станциясе -ТүбәнКамаНефтехим" акционер җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | Салкын суны транспортировкалау | 2018 | 2206,26 | 1 | - | 5,0 | - |
| | | 2019 | 2284,67 | 1 | - | 5,0 | - |
| | | 2020 | 2338,73 | 1 | - | 5,0 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге